**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**НИЖНЕКАРМАЛКИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423102, СЕЛО НИЖНЯЯ КАРМАЛКА, УЛ. ЛЕНИНА, Д.44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

423102, ТҮБӘН КАРМАЛКА АВЫЛЫ, ЛЕНИН УРАМЫ,
44 ЙОРТ

Тел.: (84396)2-39-47 ФАКС: (84396) 2-39-47
Email: Nkar.Cmn2@tatar.ru

11.02.2026 ел №18

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге
Советының «Җир салымы
турында» 2020 елның
23 октябрендәге №8 карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге № 425-ФЗ Федераль законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Түбән Кармалка авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 23 октябрендәге 8 номерлы карарына (Советның 2023 елның 22 сентябрендәге 101 номерлы, 2024 елның 28 октябрендәге 150 номерлы, 2024 елның 26 декабрендәге 159 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 статьяның 2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «2) Хисап чоры квартал буларак билгеләнгән салым түләүчеләр - оешмалар өчен салым органнары агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталлары тәмамланганнан соң салым буенча аванс түләүләре суммаларын җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасының дүрттән бер өлеше буларак исәплиләр.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль

районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.Ф. Митякин